КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 май

г.Казань

№ 409

Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, халыкның барлык катламнары өчен алардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга карата таләпләрне стандартлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

кинофильмнарны күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын;

кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын.

2. Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына муниципаль учреждениеләр күрсәтә торган тиешле муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү өчен кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү, кинофильмнар күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү стандартларын куллануны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 8 июль, 467 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 8 июль, 467 нче карары белән расланган Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 29 сентябрь, 721 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 нче пункты.

4. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин